РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

7 ноябрь, 2025 ел Кукмара ш. № 13

Кукмара район Советының 2008 елның 18 гыйнварындагы 05 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районында социаль ипотека буенча торак урыннары сатып алуда гражданнарны кичекмәстән ярдәмгә мохтаҗлар дип тану тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде**:

1. Кукмара район Советының 2008 елның 18 гыйнварындагы 05 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районында социаль ипотека буенча торак урыннары сатып алуда гражданнарны кичекмәстән ярдәмгә мохтаҗлар дип тану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче пунктта:

а пунктчасында «торакны исәпкә алу бүлеге» сүзләрен «инфраструктура үсеше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

б пунктчасында «торакны исәпкә алу бүлеге» сүзләрен «инфраструктура үсеше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 5 нче пунктта:

20 нче абзацта «Федераль теркәү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә» сүзләрен «Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә» сүзләренә алмаштырырга.

24 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- эш бирүче тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе (барлык битләр) йә хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр;»

1.3 6 нчы пунктта «торакны исәпкә алу бүлеге» сүзләрен «инфраструктура үсеше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

1.4 8 нче пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район башлыгы С.Д. Димитриев